КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 май г.Казань № 475

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм һәм тормыш сыйфатын яхшырту программаларын гамәлгә ашыручы көндезге тору бүлекчәләрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 16 февраль, 131 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм һәм тормыш сыйфатын яхшырту программаларын гамәлгә ашыручы көндезге тору бүлекчәләрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 16 февраль, 131 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗлары өчен норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентларының 1 пунктындагы 1.3 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвеше белән «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм һәм тормыш сыйфатын яхшырту программаларын гамәлгә ашыручы көндезге тору бүлекчәләрендә ятак-көннәр санының «Казан шәһәре» юлында «1 890» саннарын «100» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә (бу карарда гамәле 2022 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган 1 пунктның икенче абзацыннан тыш) кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин